ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2025 Балык Бистәсе штп. № 315пи

2026 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2026 елга расларга:
- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;
- балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,85 күләмендә төзәтмә коэффициентны.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган нормативлар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 20.12.2025 №
315пи карары белән
расланган

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар ( 1 укучыга елына, сумнарда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | жиде еллык уку срогы | сигез еллык уку срогы | Башлангыч һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | 99 826 | 95 524 | 96 798 | 111 416 | 115 995 | 150 794 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 49 900 | 42 477 | 39 295 | 43 367 | 99 300 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 97 308 | 79 435 | 84 263 | 342 950 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 43 534 | | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 101 217 | 97 465 | 100 551 | 165 858 |
| Фольклор сәнгать | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 156 530 | | 151 191 | | | 263 997 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театраль сәнгать | шәһәр җирлеге | 77 614 | 70 087 | 72 585 | 72 557 | 76 069 | 107 794 |
| Театраль сәнгать | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |